**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Победа торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**20 октябрь 2023 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 20 октябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

1. «Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаиләләре махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) Җиңү бистәсендә урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Күпфатирлы торак йортларны су кертү системаларын төзү һәм ремонтлау: Җиңү бистәсе, Үзәк ур., 11 һәм 13 й.

3) Җиңү торак пункты халыкның күпләп ял итү урыннарын, аларга якын урнашкан территорияләрны төзекләндерү.

3) Җиңү торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

4) Җиңү бистәсендә традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 527 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 421.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 421, «КАРШЫ» позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңу торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - гамәлдә дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сораулар буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез, 2024 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, гаиләләре махсус хәрби операциягә юнәлтелгән гаилә әгъзасыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Җиңү торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

1) Җиңү бистәсендә урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы;

2) Күпфатирлы торак йортларны сулыкларга бүлеп бирү системаларын төзү һәм ремонтлау: Җиңү бистәсе, Үзәк ур., 11 һәм 13 й.

3) Җиңү торак пункты халыкның күпләп ял итү урыннарын, аларга якын урнашкан территорияләрны төзекләндерү.

3) Җиңү торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

4) Җиңү бистәсендә традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү.

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Вахитов авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районынын Вахитов авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы: Г.И. Аскарова